**СОВЕТ**
**ЕКАТЕРИНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423196, РТ Новошешминский район
с. Сл. Екатерининская, ул. Приовражная д. 9.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЕКАТЕРИНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423196, РТ Яңа Чишмә районы Екатерина
Бестәсе авылы, Приовражная урамы, 9

Тел.:(8-4348)3-67-36,факс:(8-4348)3-67-36.Ekat.Nsm@tatar.ru.

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

“ 14 нче ноябрь, 2018 нче ел № 60-105

**“Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 25 нче ноябрендәге “Җир салымы турында” 22-39 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында”**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы “Екатериновка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

I. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 25 нче ноябрендәге «Җир салымы турында» гы 22-39 нче номерлы карарына (2017 нче елның 5 нчы сентябрендәге 33-60 нче номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 25 нче ноябрендәге “Җир салымы турында” 22-39 нче номерлы карарының 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Салым ташламалары бирергә:

3.1. шәхси торак йортлар, шәхси ярдәмче хуҗалык, гараж һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә җир салымын түләүдән, кануннарда каралган салым түләүчеләр

категорияләреннән тыш, түбәндәге салым түләүчеләргә - физик затлар категориясенә дә азат итү рәвешендә:

- ялгызлыкта яшәүче 75 яшьтән өлкәнрәк яшьтәге гражданнар;
- ятим балалар;
- табигый бәла-казалардан зыян күргән гражданнар;
- Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, шулай ук сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм инвалидлары;
- янгын сагы җәмәгать берләшмәләре һәм ирекле янгын сүндерүчеләр әгъзалары.

Әлеге карарның 3.1 пунктында санап үтелгән салым түләүчеләр категориясенә керә торган һәм Екатериновка авыл җирлеге территориясендә берничә җир кишәрлеге (өлешләр) булган) физик затларга салым ташламасы салым түләүченең теләге буенча бары тик бер җир кишәрлеге (өлеш) өчен генә бирелә.

3.2. салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә 100% күләмендә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә:

- оешмалар һәм учреждениеләрнең гражданнар күмелгән җир кишәрлекләренә карата".

II. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм физик затларның җир салымын исәпләүгә бәйле хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла, ләкин рәсми басылып чыкканнан соң бер айдан да иртәрәк түгел.

III. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы" "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә)

IV. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Екатериновка авыл җирлеге башлыгы А.А.Хорьков

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЕКАТЕРИНИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Р 05-12005/14
СОВЕТ ЕКАТЕРИНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ